# Туган җирем, мәктәбем, һөнәри эшчәнлегем.

**МБГББУ “Кнәз урта гомуми белем бирү мәктәбе”**
**татар теле һәм әдәбияты укытучысы**
**Шәймарданова Рамилә Фәтхетдин кызы**



Күрче, дөнья нинди матур,
Тирә ягың гөл генә,
Гөлбакчадай ямьле була
Бары туган җир генә.



***Мин – Шәймарданова  Рамилә Фәтхетдин кызы.***
***Тумышым белән Алабуга районы Сарсаз авылыннан.***




***Авылым табигатьнең бик матур бер почмагында урнашкан. Язын авыл кырындагы алма бакчасы ап-ак чәчәккә күмелә. Талларга кунып сандугачлар сайрый. Авылым табигате кочагында иркәләнеп-назланып, яланаяк йөгереп үскән кыз мин.***

И авылым, син еракта инде,
Сагындырып төшкә керәсең.
Язмышларга ниләр язылганны,
Туган нигез – күбрәк беләсең.




***Язмыш җилләре кешене, туган нигезеннән аерып алып, кая гына илтеп ташламый. 10нчы сыйныфны тәмамлаганнан соң мин Яр Чаллы шәһәренә килдем.***








***Һөнәри эшчәнлегем 1996нчы елны Яр Чаллы шәһәренең 54нче татар гимназиясендә белем бирү эшеннән азат ителгән сыйныф җитәкчесе буларак башланып китте.***



***2004нче елдан  МБГББУ “Кнәз  урта гомуми белем бирү мәктәбе”ндә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшлим.***




***Мәктәбебез коллективы бик дус***

***һәм ярдәмчел.***

Дөнья иң-иң матур ил
Ул – минем туган илем.
Дөнья иң-иң матур тел
Ул – минем туган телем.

Энҗе Мөэминова







***Эшемдә төп максатым: туган телгә мәхәббәт тәрбияләү. Һөнәри эшчәнлегемдә уен һәм информацион коммуникатив технологияләрне, проектлар методын яратып кулланам.***

# Укучылар иҗади эшләре белән таныштыра





# Төрле уеннар уйныйбыз



# Класстан тыш чаралар бик күңелле үтә








# Төрле әкиятләрне сәхнәләштерәбез


















***Укучылар төрле олимпиадаларда теләп катнашалар. Призлы урыннар алалар, җиңүчеләр булалар. Аларның уңышлары минем өчен дә шатлык.***






























***Мин үзем дә төрле һөнәри бәйгеләрдә катнашырга тырышам. Бу бәйгеләр минем һөнәри осталыгымны камилләштерә ярдәм итә.***

## СҮЗ АЗАГЫНДА

**Миннән сиңа дустым бер теләк:**
**Туган жирнең,**
**туган телнең**
**кадерен белергә кирәк.**